Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге составына керүче Елантау торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлегенең Елантау торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлегенең Елантау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, анда катнашучылар һәм инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, балачактан инвалидлар, 16 яшькә кадәр инвалид бала ата-аналары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булган солдатлардан тыш, мобилизованных гражданнар һәм хатыны/ире мобилизованного, 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. 18 яшькә кадәр өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, 18 яшькә кадәр балаларның ялгыз аналары, мәшгульлек үзәгендә исәптә торучы гражданнар, сугышчы-интернационалистлар һәм "кайнар нокталар" да чакырылыш буенча хәрби хезмәт үткәннәр, хезмәт ветераннары, ата-аналар мобилизованных гражданнарның билгеләнгән суммадан 50 % күләмендә түлиләр.
2. Алынган акчаларны зиратка кадәр юл салу һәм контейнер мәйданчыкларына керү өчен таш сатып алуга юнәлтергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Елантау авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　В.А. Лебедев